ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕМАШЛЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422658, с. Большой Машляк,
ул. Центральная, дом 20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗУР МӘШЛӘК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422658, Зур Мәшләк,
Центральная урамы, 20 нче йорт,

Тел.: (84361) 33613, факс: (84361) 33613 , e-mail:BmSl.Rs@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.10.2019 Зур Мәшләк авылы № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Зур Мәшләк, Югары Мәшләк, Бикчурай авылларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Зур Мәшләк авыл җирлеге » муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның 9 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Бикчурай торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләргә.
2. 2019 елның 16 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Зур Мәшләк торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә.
3. 2019 елның 16 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Зур Мәшләк торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә

4. Халык җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге составына керүче Зур Мәшләк, Югары Мәшләк, Бикчурай авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлар,1 нче группа инвалидлар, тумыштан инвалидлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы»:

- Зур Мәшләк, Югары Мәшләк, Бикчурай авылларында энергияне саклаучы яктырткычларына хезмәт күрсәтү;
-кышын авыл җирлеге торак пунктларында урамнарның йөри торган өлешләрен карап торуга (кардан арындыруга);
- Зур Мәшләк авылының зират ягына чыгу күперенә капиталь ремонт ясау.

«ӘЙЕ» «ЮК».

6. Әлеге карар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә урнаштырырга.
7. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районының
Зур Мәшләк авыл җирлеге башлыгы М.Г.Заһидуллин